СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ХАЛЫК ГАЗЕТАСЫ
НАРОДНАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА

Газета 1931 елның 1 июленнән бирле чыга | №138 (7467) | 19 ноябрь. 1992 ел. ПӘНҖЕШӘМБЕ | Бәясе 4 тиен.

**ДУСЛЫК**

## Хөрмәтле укучылар!

**Кабат исегезгә төшерәбез: «Дуслык», «Дружба», «Туслах» район газетасына язылу дәвам итә. Газетага үзвакытында язылып калырга киңәш итәбез. Аның еллык бәясе 78 сум.**

## Күрсәткечләр куандырырлык

Норлат шикәр заводы коллективы үзләренең профессиональ бәйрәмнәре — авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү промышленносте хезмәткәрләре көнен хезмәттә матур күрсәткечләр белән каршылады. Шикәр кайнату сезоны башланганнан алып планда каралган 58950 тонна урынына 74352 тонна шикәр чөгендере эшкәртелде. Бу планга карата 126,1 процент. Планда билгеләнгән 7750 тонна урынына 8534 тонна шикәр комы эшкәртелде һәм план 110,1 процентка үтәлде.

Сменалар арасында сентябрь-октябрь йомгаклары буенча беренче номерлы смена (начальнигы Н. А. Волков) җиңеп чыкты. Коллектив шикәр комы җитештерү буенча планны 115 процентка җиткерде.

Икенче урында Ф. Ф Крайнов җитәкчелегендәге өченче смена бар. Коллектив ике айлык җитештерү планын 112,3 процентка үтәде.

Билгеле булганча, шикәр заводы коллективы агымдагы елда яңа төр продукция — сырецтан шикәр комы җитештерүне үзләштерде. Ай ярымда 7696 тонна сырец эшкәртелде.

Эш дәвамында хезмәт җитештерүчәнлеге 8,8 процентка үсте.

Парлау аппаратчысы К. Г. Минәхмәтов, центрифуга аппаратчысы З. И. Васильева, заводның баш механигы В. П. Матюшкин, КИП слесаре В. П. Зорин, мехмастерской токаре А. И. Грачев кебек тырышлар план үтәлешләренә лаеклы өлеш кертәләр.

Коллектив киләчәктә дә эштә темпны сүрелдермәс өчен көчен кызганмас.

**Т. БОГАТИКОВА,**
шикәр заводының планэкономика бүлеге начальнигы.



Газ һәм электр белән эретеп ябыштыручы Фәнис Минсәлихович Нурмөхәммәтов турында чирмешәнлеләр зур ихтирам белән «алтын куллы ул» — диләр. Ул механизаторларның барлык заказларын җиренә җиткереп башкара, алар аның эшеннән канәгать. Урак өстендә аның көннәре аеруча мәшәкатьле үтә: чөнки ул мастерскойда гына түгел, кирәк булган да кырга чыгып та механизаторларга хезмәт күрсәтә.

РӘСЕМДӘ: «Чирмешән» колхозы эретеп ябыштыручысы Фәнис Нурмөхәммәтов.

## Җирләр ничек ашлана?

**Органик ашлама чыгару буенча удар икеайлыкның барышы.**

Беренче багана — хуҗалыклар исемнәре, икенче — органика чыгару задание, өченче — аның буенча җиткерелгән үтәлеше (тонналарда). Мәгълүматлар 1992 елның 16 ноябренә.

| | | |
|---|---|---|
| Синдряков исем. | 3500 | 80 |
| Ульянов исем. | 4100 | — |
| «Правда» | 3200 | — |
| «Восход» | 3100 | — |
| Мичурин исем. | 3200 | 2100 |
| «Россия» | 2800 | 600 |
| Хафизов исем. | 2000 | — |
| «Путь к коммунизму» | 4400 | 1400 |
| Муса Җәлил исем. | 2500 | — |
| «Родина» | 2400 | — |
| «Игенче» | 4100 | — |
| «Большевик» | 3100 | — |
| «Заветы Ильича» | 3200 | — |
| «Знамя Октября» | 3700 | — |
| «Алга» | 6000 | 2014 |
| «Комбайн» | 4700 | 800 |
| XXI партсъезд исем. | 6000 | — |
| «Татарстан» | 3300 | — |
| «40 лет Победы» | 3000 | — |
| «Чишмә» | 3700 | — |
| «Таң» | 2500 | — |
| «Москва» | 2000 | 1092 |
| «Үрнәк» | 1900 | 600 |
| «Лесная поляна» | 600 | — |
| «Кондырча» | 1800 | — |
| Кузнецов исем. | 3000 | — |
| «Заря» | 2500 | 1000 |
| «Чирмешән» | 1800 | 80 |
| «Ленинский путь» | 3000 | — |
| «Первое мая» | 3600 | 300 |
| «Яшь көч» | 1500 | — |
| «Төрнәс» совхозы | 4800 | — |
| «Мамык» совхозы | 3900 | 410 |
| «Рассвет» совхозы | 6100 | — |
| «Сөлчә» совхозы | 2800 | 100 |
| Хуҗалыкара берләшмә | 3900 | — |
| «Дуслык» | 1400 | — |
| Район буенча | 120000 | 10576 |

* * *

Басуларга органика чыгару буенча игълан ителгән удар икеайлыкның ике атнасы үтеп тә китте. Бу чорда колхоз, совхозлар: әлегә кырларга 10576 тоннадан артык өстәмә сый чыгардылар, күрәсез бу бик аз. Бу эш 13 хуҗалыкта гына тиешенчә оештырылган. Ә Ульянов исемендәге, «Правда», «Восход», Хафизов исемендәге, Муса Җәлил исемендәге, «Родина», «Игенче», «Большевик», «Заветы Ильича», «Знамя Октября», XXI партсъезд исемендәге, «Татарстан», «40 лет Победы», «Чишмә», «Таң», «Лесная поляна», «Кондырча», Кузнецов исемендәге, «Ленинский путь», «Яшь көч», «Дуслык» колхозларында, «Төрнәс» совхозы, хуҗалыкара берләшмә, кырларга органик ашлама чыгаруга бөтенләй керешмәделәр әле. «Путь к коммунизму» колхозына бу эшне башкаруда «Сельхозхимия» берләшмәсе, «Москва» колхозына «Сельхозтехника» берләшмәсе ярдәм күрсәтә. Хуҗалык җитәкчеләре һәм белгечләре онытмасыннар: мул уңыш алырга телибез икән, басуларны мул итеп сыйларга тиешбез.

## «Үзебезнеке, комбинатныкы»

**Шәһәрдәге азык комбинаты җитештергән колбаса, сер түгел, күбебезнең күңеленә ятмый. «Кыйммәт булса да, түбән тоеп ашарлык булсын, ичмаса» дигән сүзләрне еш ишетәбез халыктан. Инде менә күбебезнең теләге тормышка ашар төсле — ит комбинаты каршында яңа колбаса цехы эшли башлады.**

Менә алар — яңа цехта җитештерелгән тәүге тугыз сорт колбаса: рәсемдәгечә теләсә кемнең аппетитын кузгатырлык рәвештә, тәме дә без Норлатта татырга күнмәгәнчә үзенчәлекле. Исемнәре күпләргә бәлки таныштадыр: «Одесская», «Горская», «Отдельная», «Русская», «Любительская», «Московская», «Любительский» сосиские, ветчина һәм башкалар. «Татмясопром» берләшмәсе инженер-технологы Н. А. Кукушкина аларның һәрберсенең үзенчәлекләрен, әзерләү технологиясен аңлата. Әле бүген янә 4—5 сорт яңа төр колбаса эшләячәкләр икән, алар арасында «Останкинская», «Молочная», «Армавирская» кебек халык арасында популяр сортлар да бар. Шулкадәр сортта, шундый сыйфатлы колбаса чыннан да бездә җитештерелер микәнни?

— Сорт ягына килгәндә, анысын бик төрләндерүне вәгъдә итеп бетереп булмый, халык кайсыларын аерата яратып алыр — шуларны күбрәк җитештерербез, — ди комбинат директоры Р. С. Чахмахчев. — Ә сыйфатын ничек тә шул дәрәҗәдә сакларга тырышачакбыз.

Ул бу җәһәттән күрелгән хәстәрлекне сөйләп аңлата. Яңа колбаса цехында заманча өр-яңа җиһазлар, колбаса цехы мастеры М. А. Ануфриева күптәннән эшләүче, тәҗрибәле мастер. Инде продукцияне заманча, технологик таләпләр нигезендә җитештерүгә яңа яшь мастер — әле генә Мәскәүдә институт тәмамлап, ит промышленносте технологы белгечлегенә ия булып эшли башлаган Л. Эминованың да булышлыгы тимичә калмас. Әнә шулай бергәләп район халкын сыйфатлы, тәмле колбаса белән тәэмин итәргә ниятләре комбинатлыларның. Атна ахырында беренче партия продукцияне сәүдә нокталарына озатырга уйлыйлар.

— Ничек уйлыйсыз, шундый сыйфатны саклап халыкка охшарлык продукция җитештерә алырсызмы?

Мастер Мария Артемьевна һич шикләнмичә җавап бирә:

— Әлбәттә. Элекке иске цехта да сменага 1,5 тонна колбаса җитештерә идек, аның сыйфатыннан күпләр канәгать иде) (ашап караучылар, әлбәттә — ред.). Инде мондый шартларда сыйфатсыз ризык җитештерсәк оят булыр.

Шартлар димәктән, ит комбинатында соңгы елларда ул чыннан да күп үзгәреш кичерде. Хәзер биредә сыйфатлы азык продукциясе җитештерү өчен төп таләпләр — җылылык, салкынлык, пар, су — һәммәсе 100 процентта көйләнгән. Былтыр-быел гына биредә тире тозлау цехы, чистарту корылмалары төзелде, МСО белән берлектә 33 фатирлы йорт файдалануга тапшырылды. Цехларда технология җайга салынды, төп эшләр механикалаштырылды, икенчел чимал эшкәртү киң җәелдерелде, калдыксыз продукция — терлек суюдан калган мөгез, ял, тояк һәм башкалар — һәммәсе файдалы әйләнешкә кертелде. Киләчәктә завод дирекциясенең эшкәртүне киңәйтү — барлык итне үзендә эшкәртү юнәлешенә янә зур-зур планнар бар, колбаса цехы — шул зур планнарның беренче карлыгачы, елга сузылган төзү, әзләнү, монтажлау, табу, кайгырту җимеше.

Цех чыннан да көткән өметләрне акларлык сыйфатлы, теләсә кем табынында затлы, көтелгән ризык булырлык продукция җитештерер дип ышанабыз.

— Кайдан килгән колбаса бу? Бигрәк әйбәт, — дигәндә, — үзебезнеке, үз ит комбинатыбызныкы, — дип җавап бирү һәр норлатлы өчен күңелле булыр.

**С. НУРУЛЛИНА**

### ЧЕРЕМӘ — КЫРГА

Мичурин исемендәге колхозда басуларны ашлауга зур игътибар бирелә. Черемә ташучы махсус звеноның җитештерүчән хезмәте өчен барлык шартлар тудырылган, шулай ук материаль кызыксындыру чаралары да каралган. Геннадий Сафронович Леваков ДТ-75 төягеч тракторында черемәне төйи, ә КамАЗ шоферлары Василий Васильев, Валерий һәм Владимир Тимофеевлар черемәне ташып торалар.

**В. ГАВРИЛОВ.**

